РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 07 » 09 2021 г. № 702

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында үлүчеләр саны буенча ведомствоара комиссия турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы №1 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы халкының үлем сәбәпләрен мониторинглауны, өйрәнүне оештыру һәм аны киметүгә юнәлдерелгән нәтиҗәле чараларны үз вакытында кабул итү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кешеләр үлеме дәрәҗәсе буенча ведомствоара комиссия составын (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кешеләр үлеме дәрәҗәсе буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмәне (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль сораулар буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе С.П. Самонина

С.А. Рузанов
2-73-11

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башкарма
комитетының «____»_________20___
ел № _карарына

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кешеләр үлеме дәрәҗәсе буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Рузанов С.А. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| Шакирова С.З. | «Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Рахмаева М.А. | «Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ оештыру-методика кабинетының өлкән фельдшеры, комиссия секретаре (килешү буенча); |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Клещевников К.А. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Ютазы районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Миңневәлиев Н.Н. | «Ютазы районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ директоры (килешү буенча); |
| Рәшитова З. Ә. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Вилданов И.Г. | «Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча); |
| Фәхертдинова Г.С. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлеге начальнигы. |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башкарма
комитетының «____»_________20___
ел № _карарына

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кешеләр үлеме дәрәҗәсе буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында үлүчеләр саны буенча ведомствоара комиссия (алга таба - комиссия) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә.
1.2. Комиссияне Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары җитәкли.
1.3. Комиссия составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, шулай ук килешү буенча хокук саклау органнары, сәламәтлек саклау, социаль яклау учреждениеләре, мәшгульлек үзәге вәкилләре кертелә. Комиссия әгъзалары үз эшчәнлекләрен җәмәгать башлангычларында гамәлгә ашыралар һәм комиссия утырышларында шәхсән катнашалар. Комиссия утырышларына прокуратура, суд, эшкуарлык структуралары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре чакырылырга мөмкин.
1.4. Комиссия карарларының үтәлүе мәҗбүри.

## 2. Комиссиянең бурычлары

2.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кешеләр үлеме сәбәпләренә анализ ясау.
2.2. Кешеләр үлемен стабильләштерүгә һәм киметүгә, медицина ярдәменең сыйфатын яхшыртуга һәм оештыруга юнәлдерелгән ашыгыч һәм озак сроклы идарә итү карарларын эшләү һәм кабул итү.

## 3. Хокуклар һәм бурычлар

3.1. Комиссия хокуклы:
- ведомство карамагына һәм оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә оешмалар һәм учреждениеләр тарафыннан башкару өчен мәҗбүри булган карарларны чыгарырга;
- ведомство карамагына һәм оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә, оешмалар җитәкчеләреннән һәм учреждениеләр җитәкчеләреннән комиссия эше өчен кирәкле материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга.
3.2. Комиссия түбәндәгеләргә бурычлы:
- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында, шул исәптән хезмәткә сәләтле яшьтәге халыкның үлем күрсәткечләренә динамик анализ ясарга.
- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында халыкка медицина ярдәме күрсәтүгә анализ ясарга.

## 4. Комиссия эшен оештыру

4.1. Комиссия утырышлары зарурилык саен уздырыла, ләкин ярты елга бер тапкырдан да ким түгел.
4.2. Комиссия утырышы, комиссия әгъзаларының гомуми составының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы дип санала. Комиссиянең барлык карарлары комиссия әгъзаларының гомуми составының күпчелек тавышы белән кабул ителә.
4.3. Комиссия секретаре комиссия утырышының билгеләнгән датасына кимендә 7 көн кала комиссия рәисенә карала торган мәсьәлә нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында халык үлемен анализлау статистик материалын тапшыра.
4.4. Комиссиянең чираттан тыш утырышы буенча, комиссия рәисенә нигезле тәкъдим кертеп, комиссия әгъзасы тарафыннан инициатива ясалырга мөмкин.
4.5. Комиссиянең чираттан тыш утырышын уздыру турында карар комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә.
4.6. Комиссия утырышлары ачык утырышлар рәвешендә дә, ябык утырышлар рәвешендә дә үткәрелергә мөмкин. Комиссия утырышын уздыру формасы турындагы карар комиссия әгъзаларының гомуми составындагы күпчелек тавыш белән кабул ителә.
4.7. Комиссия утырышлары «Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ бинасында да, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетында да үткәрелә.